Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
Куакбаш авыл җирлеге
Сходнево-Чертанлы авылында гражданнар җыены
КАРАРЫ

2021 елның 20 ноябре №1

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Куакбаш авыл җирлегенең Сходнево-Чертанлы авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 елның 20 ноябрендә 2022 елда үзара салым кертүгә Лениногорск муниципаль районы Куакбаш авыл җирлегенең Сходнево-Чертанлы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән, көндегге формада укучы студентлардан тыш, 2000 сум күләмендә акча кертү һәм җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме:

2.1.Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- Сходнево-Чертанлы авылында (Пушкин ур., Ирек ур., Кутузов ур.) вак таш җәеп, юлларны ремонтлау;
-Сходнево-Чертанлы авылында (Пушкин ур., Ирек ур., Кутузов ур.) юлларны кардан чистарту.

«ӘЙЕ» «ЮК».

соравы буенча узган гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

Халык җыены беркетмәсе нигезендә:
Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 74 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны - 44 кеше.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучылар бертавыштан «ӘЙЕ» позициясе өчен тавыш бирделәр.
Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Куакбаш авыл җирлегенең Сходнево-Чертанлы авылында гражданнар җыены карар бирде:
1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Куакбаш авыл җирлеге составына керүче Сходнево-Чертанлы авылында гражданнар җыенын узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.
2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: 2022 елда үзара салым кертүгә Лениногорск муниципаль районы Куакбаш авыл җирлегенең Сходнево-Чертанлы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән, көндегге формада укучы студентлардан тыш, 2000 сум күләмендә акча кертү һәм җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне

башкару өчен җибәрү белән килешәсезме:

2.1.Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- Сходнево-Чертанлы авылында (Пушкин ур., Ирек ур., Кутузов ур.) вак таш җәеп, юлларны ремонтлау;
-Сходнево-Чертанлы авылында (Пушкин ур., Ирек ур., Кутузов ур.) юлларны кардан чистарту.

«ӘЙЕ» «ЮК».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Куакбаш авылы, Карл Маркс урамы, 15 йорт адресы буенча урнашкан җирле үзидарә бинасында, Сходнево-Чертанлы авылы Ирек урамы, 5а буенча урнашкан авыл клубы, Чүте авылында Тынычлык урамы 8А буенча урнашкан авыл клубы бинасында урнашкан мәгълүмат стендларында, Лениногорск муниципаль районының рәсми Интернет-сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.r) урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Куакбаш авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Әхмәтҗанова